ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# ПРИКАЗ

27.04.2026 Казан ш. № 10- 07/43

Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең 23.05.2016 елның 12-07/38 номерлы “Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүне, аларның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшереп торуын тәэмин итү һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе комиссиясе турында” боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең 23.05.2016 елның 12-07/38 номерлы “Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүне, аларның әйләнешен һәм сыйфатын дәүләт тикшереп торуын тәэмин итү һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе комиссиясе турында” боерыгына (Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең 26.07.2018 № 12-07/130, 13.03.2023 № 10-07/29, 25.07.2024 № 10-07/94, 08.09.2025 № 10-07/61 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча кулланучылар хокукларын яклау комиссиясе турындагы Нигезләмәдә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.Комиссия составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән раслана. Күрсәтелгән боерык белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе билгеләп куела. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.”;

7 нче пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары (комиссия рәисе), Татарстан”Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары), кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (комиссия секретаре), дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәләр, юридик (хокукый) һәм җитәкче билгели торган башка бүлекчәләр вәкилләре;»;

15 пунктның “а” пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;”;

21 нче пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;”;

2.Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча кулланучылар хокукларын яклау комиссиясе составын кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4.Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең коррупциячел

һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка әлеге боерык дәүләт теркәвенә алынганнан соң Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Ж. Ю. Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 23.05.2016 № 12-07/38 боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 27.04.2026 № 10-07/43 боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерүгә, әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча кулланучылар хокукларын яклау комиссиясе
СОСТАВЫ:

| | |
|---|---|
| Арсланов Рөстәм Әсхәт улы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары (комиссия рәисе) |
| Эйдинов Борис Григорьевич | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлеге башлыгы (комиссия рәисе урынбасары) |
| Кузнецов Владимир Витальевич | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлегенең әйдәүче киңәшчесе (комиссия секретаре) |
| Арсланова Розалия Мәхмүт кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгы (комиссия әгъзасы) |
| Корнилов Юрий Владимирович | Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле (килешү буенча) (комиссия әгъзасы) |
| Нигъмәтҗанов Алмаз Альберт улы | Казан (Идел буе) федераль университеты юридик факультетының конституциячел һәм административ хокук кафедрасы доценты (килешү буенча) (комиссия әгъзасы) |
| Сәрвәрова Наилә Наил кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) (комиссия әгъзасы) |
| Семенова Альбина Наил кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге башлыгы (комиссия әгъзасы) |
| Токмин Данила Геннадьевич | “Татэкспертцентр” ДБУ директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет рәисе урынбасары (килешү буенча) (комиссия әгъзасы) |
| Фомина Татьяна Владимировна | Казан (Идел буе) федераль университетының финанс менеджменты кафедрасының укыту-методик эш буенча 1 категорияле белгече (килешү буенча) (комиссия әгъзасы); |
| Хәбибуллина Татьяна Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең контроль-инспекция бүлеге башлыгы (комиссия әгъзасы) |
| Хуҗина Рима Нурулла кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең финанс контроле бүлеге башлыгы (комиссия әгъзасы) |